**8нче билет**

<table>
<tr><th>Биремнәр</th><th>җаваплар</th></tr>
<tr><td>

1. **Теркәгечләрне таблицага урнаштырыгыз.**

<table>
<tr><td>Җыючы</td><td>Каршы куючы</td><td>Бүлүче</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

Теркәгечләр: я, һәм, ләкин, әмма, да, дә, әллә, бәлки, яки.

</td><td>

<table>
<tr><td>Җыючы</td><td>Каршы куючы</td><td>Бүлүче</td></tr>
<tr><td>һәм, да, дә,</td><td>ләкин, әмма, бәлки,</td><td>я, әллә, яки</td></tr>
</table>

</td></tr>
<tr><td>

2. **Текстны укыгыз, эчтәлеген сөйләгез.**

Профессор Асиягә сораулар бирде.

- Балачакта малайлар белән уйнадыгызмы?
- Әлбәттә.
- Кем дип үртиләр иде?
- Чеби Асия...
- А мороженое яратасыңмы? – дип елмайды профессор.
- Аны кем яратмый?
- Ә тамак авыртамы?
- Авырта, әни кайнар сөт эчерә.
- Димәк ангина белән еш авырыйсың. Ә театрга еш йөрисеңме?
- Театрны бик яратам.
- Әлбәттә, кыш көне капрон оек киеп. Аякларың авыртамы?
- Авырта.

</td><td>

**2.Прочитайте текст, перескажите содержание.**

Асия авырый. Ул доктор янына килде. Профессор кызга сораулар бирде. Асия җавап кайтарды. Ул балачакта малайлар белән уйнарга, мороженое ашарга, театрга йөрергә яраткан. Мороженое ашагач, тамагы авырткан; ангина белән еш авырган. Театрга йөргәндә кыш көне капрон оек кигән, шунлыктан хәзер аяклары да авырта

</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| **3. Шигырьнең эчтәлеген сөйләгез, теләгән өлешен ятлагыз.**<br>Әни кирәк<br>Көннәр якты булсын өчен,<br>Йокы татлы булсын өчен,<br>Әни кирәк, әни кирәк.<br>Йокы татлы булсын өчен,<br>Әни кирәк. Әни кирәк.<br>Җил-яңгырдан саклар өчен,<br>Усаллардан яклар өчен<br>Әни кирәк.<br>Ашлар тәмле былсын өчен,<br>Дөнья ямьле булсын өчен<br>Гөлләр чәчәк атсын өчен,<br>Бәхет-шатлык артсын өчен,<br>Әни кирәк, әни кирәк.<br>Иң кадерле кеше җирдә –<br>Әни димәк.<br>Р. Миңнуллин | **3.Перескажите содержание стихотворения, выучите понравившийся отрывок.** |
| **4. Кушма җөмләләрне тәрҗемә итегез, төрен билгеләгез.**<br>1) Когда я пришёл домой, мама сидела у окна.<br>2) Когда вы будете готовы, тогда я вас послушаю.<br>3) Балалар музейга кергәч, аларны экскурсовод каршылады.<br>4) Имтиханнар беткәч, безгә аттестлар тапшылдылар. | **4. Переведите сложные предложения, определите вид.**<br>1) Мин өйгә кайтканда әнием тәрәзә янында утыра иде.<br>2) Сез әзер булгач, мин сезне тыңлармын.<br>3) Когда дети вошли в музей, ихвстречала экскурсовод.<br>4) Когда закончились экзамены, нам вручили аттестаты. |
| **5. Как скажешь другу о том, что:**<br>- ты пойдёшь на дискотеку, если разрешит мама;<br>- если он хочет, ты поможешь решить задачу;<br>- если к вам придут гости, то не пойдёшь кататься на лыжах. | **5.**<br>Айдар, әнием рөхсәт итсә, мин дискотекага барырмын.<br>Айдар, теләсәң, мин мәсьәләне чишәрмен.<br>Айдар, кунаклар килсә, чаңгы шуарга бармыйм. |